МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__23.11.2021__ г. Казань № __958од__

Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгының 2020 елның 18 ноябрендә расланган 837 од номерлы боерыгы нигезендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтен күрсәтү эшчәнлеген камилләштерү максатында

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгының 2020 елның 18 ноябрендә расланган 837 од номерлы боерыгы нигезендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакындагы «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип теркәргә.

Министр вазифаларын башкаручы Ю.И.Әдһәмова

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
____________2021 елның
____________номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгының 2020 елның 18 ноябрендә расланган 837 од номерлы боерыгы нигезендә «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктында 1.3.5 пунктчасының беренче абзацында «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү (функцияләре) порталында» дип өстәргә;

1.5 пунктын түбәндәге редакциядә язырга:

«1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәтен күрсәтү турында телдән, язмача яисә электрон формада гариза белән мөрәҗәгать итүче социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма (оешманың вәкаләтле вәкилләре);

БИАС (ЕСИА) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы.

техник хата – Министрлык тарафыннан социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турындагы бәяләмәсендә күрсәтелгән мәгълүматларга туры килмәве яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилле хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавына китергән хаталар (ялгыш язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хаталар);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендә имзаланган 1376 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең территориаль мөстәкыйль структур бүлекчәсе (офисы).

Башка төшенчәләр һәм терминнар 2010 елның 27 июлендә гамәлгә кергән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»

Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә кулланыла.

2 бүлекне түбәндәге редакциядә язырга:

«2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә (алга таба – бәяләмә) бирү

2.2. Башкарма хакимият органының атамасы

Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак шушы Регламентның 2 нче кушымтасы үрнәге буенча бәяләмә яисә әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы үрнәге буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамә.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүнең вакытын, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенә бәйле булган документларны бирү (юллау) вакыты.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә бәяләмә бирү турында теркәлгән гаризаны кабул иткән көннән 10 эш көне тәшкил итә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварында гамәлгә кергән 89 номерлы карары белән расланган «Коммерциячел булмаган оешмалар реестры - иҗтимагый файдалы хезмәт башкаручылар турында» коммерциячел булмаган социаль юнәлешле оешманы иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүче итеп тану турында карар кабул итү Кагыйдәләренең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафынан гариза җибәрелгән очракта күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин бу вакыт 15 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Әлеге карарны кабул итү вакытын озайту турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә хәбәр итәргә тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең вакытын туктату Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүчегә гариза бирелгән көнне тапшырыла. Гаризада (почта аша, электрон почта аша, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша) күрсәтелгән элемтәгә керү ысулыннан файдаланып дәүләт хезмәте нәтиҗәсе

булган документны җибәрү Татарстан Республикасы мәдәният министры тарафыннан бәяләмә (бәяләмәне бирүдән баш тарту турында мотивлы хәбәрнамә) имзаланган көннән алып бер эш көнендә гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтне күрсәтүдә зарури, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны алу, шул исәптән электрон формада документларны тапшыру тәртибе

Дәүләт хезмәтен куллану өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге Регламентның 1 номерлы кушымтасындагы формага нигезләнеп язылган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза);

2) мөрәҗәгать итүченең учредитель документларының күчермәсе;

3) мөрәҗәгать итүче исеменнән аның вәкиле документлар тапшырган очракта, гариза бирүче исеменнән гамәлләр кылу өчен кирәкле һәм гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамә.

Гаризага оешма күрсәтә торган хезмәтләрнең җәмгыятькә иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләүдә тиешле критерийларга туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, кызыксынучы органнар каршындагы иҗтимагый совет бәяләмәләре, дипломнар, рәхмәт хатларының күчермәләре һәм башкалар) беркетелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән очракта, оешманың иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфаты тиешле критерийларга туры килүен нигезли торган өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итүче гариза үрнәген Министрлыктан шәхсән үзе килеп алала. Гариза үрнәгенең электрон формасы «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысуллар белән тапшырылырга яисә (юлланырга) мөмкин:

1) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итү яисә кәгазь чыганакларда почта аша җибәрү;

2) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша электрон рәвештә;

3) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша;

4) гомуми файдаланыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» челтәреннән электрон ысул белән.

Гаризаны Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны электрон рәвештә яисә аларның электрон күчермәләре гариза бирүче тарафыннан имзаланган, шул исәптән нотариуслар аша теркәлгән булыга тиеш; электрон имза «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендә гамәлгә кергән 63-ФЗ номерлы

Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланырга тиеш.

Гаризаны почта аша җибәргән очракта аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә расланырга тиеш.

Гаризаны һәм тиешле документларны гомуми файдаланыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша җибәргәндә, гариза һәм документлар күчермәсенең электрон рәвеше 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары нигезендә имзаланган (расланган) булырга тиеш.

Гаризаны һәм тиешле документларны Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша җибәргән очракта гаризага гади электрон имза куела.

Гади электрон имзаны алу өчен мөрәҗәгать итүче Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (ЕСИА) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарт формада үзенең шәхесен расларга тиеш.

## 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүченең аларны тапшырырга хокукы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада юллау ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма карамагында булган документлар

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша 2013 елның 5 апрелендә гамәлгә кергән 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товар, хезмәт, хезмәт күрсәтү өлкәседә контракт системасы турында» Федераль законы нигезендә коммерциячел булмаган оешманың гариза бирер алдыннан узган ике ел эчендә төзелгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавы турында белешмәләр алына (Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсе).

Мөрәҗәгать итүче үз теләге белән әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларны тапшырырга, шул исәптән, мөмкинлеге булган очракта, электрон рәвештә тапшырырга да хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдә баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче бирергә хокуклы документларның тапшыру тәртибе һәм алу ысуллары әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Министрлык мөрәҗәгать итүчедән таләп итәргә хокукы булмаган документлар:

дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны тапшыруны яки мәгълүмат бирүне таләп итү;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүматлар, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен түләү кертүне раслаган докуменлар һәм мәгълүмат тапшыруны таләп итү;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдә кирәкле документларның һәм мәгълүматның дөрес түгеллеге, җитмәве, юклыгы турында документларны беренче тапкыр кабул итүдә баш тарту вакытында хәбәр итмәгән очракта;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә расланган документларны һәм мәгълүматны, федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш, документларга тамга (имза) салу мөһим булганда яисә аларны мөрәҗәгать итүчедән бөтенләйгә алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә тиешле шарт булып торганда, документларны кәгазь чыганакларда тапшыруны таләп итү.

## 2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тиешле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәге сәбәпләр нигез булып тора:

1) мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында санап үтелгән документлар тапшырылмаган очракта;

2) документларда тиешле тәртиптә расланмаган өстәмә язылулар, сызылган җөмләләр яки сүзләр һәм төзәтмәләр булган очракта;

3) 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре нигезендә электрон имза куелмаган (расланмаган) электрон формада документлар тапшырылган очракта.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә әлеге чыганакларда тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату яисә баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җәмгыятькә файдалы хезмәтнең (күрсәтелә торган хезмәтнең күләме, вакыты, сыйфаты) эчтәлегенә туры килмәве;

б) җәмгыятькә файдалы хезмәтне башкаруда турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән гражданлык-хокукый килешүләр имзалап җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең һәм оешма хезмәткәрләренең) тиешле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмавы һәм квалификациясе булган затларның саны җитмәве;

в) бәяләмә бирелгәнче узган ике ел дәвамында оешманың суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре буенча башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип табылган, җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына карата шикаять булуы;

г) Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (булган очракта) оешма турындагы мәгълүматның ачыклык дәрәҗәсе һәм һәркем өчен ачык булуына туры килмәве;

д) бәяләмә бирелгәнче узган ике ел дәвамында оешманың 2013 елның 5 апрелендә гамәлгә кергән 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында намуссыз тәэминатчылар реестрында булуы турында мәгълүмат;

е) дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр булган документлар яисә тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыру.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту тыела.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк.

### 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүләрне алу тәртибе, күләме һәм нигезләр

Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тиешле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, әлеге хезмәтне күрсәткән өчен түләү тәртибе, күләме һәм нигезләре

Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан гариза бирелгәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алганда чиратта торуның максималь вакыты

Гариза бирүчене кабул итү (аңа хезмәт күрсәтү) чиратта тору һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чиратта тору тәртибе билгеләнмәгән.

### 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гаризасын теркәү, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты һәм тәртибе

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүчедән гариза бирелгән көнне теркәлә.

Гариза ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән очракта, ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектлардан инвалидлар файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Бина, бүлмәләр һәм хезмәтләрне инвалидлар, шул исәптән кресло-коляскаларда һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидлар өчен уңайлы итеп тәэмин ителә һәм шартлар тудырыла, шул исәптән:

1) Министрлык бинасына һәм эш бүлмәләренә уңайлы керү һәм чыгу мөмкинлеген тудыру;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү урыннарына керү максатында Министрлык бинасы һәм бүлмәләре буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшерү мөмкинлеге булу, шул исәптән кресло-коляскада йөрү;

4) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хәрәкәт итү эшчәнлеге чикләнгән булуны исәпкә алып аларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүматны тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәк булган тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләрне кабатлау;

7) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчеәрне чакыру;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендә гамәлгә кергән 386н номерлы «Озата йөрүче этләрнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» боерыгы белән расланган һәм озата йөрүче этләрнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ булганда, мондый этне Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә кертү;

9) хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрне башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларның һәм дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кулланыла торган акчаларның инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүдә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән үзара аралашулары һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен файдалану, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә (шул исәптән тулысынча), 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында каралган, берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү турындагы гариза ярдәмендә гариза бирүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип) башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге

Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

биналарның җәмәгать транспортына якын урыннарда урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар керә-чыга, хәрәкәт итә алырлык булуы;

шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең һәм белгечләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу; электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге; мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге; инвалидларга дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

Түбәндәгеләр дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм карап тикшерү вакытын үтәү; дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү вакытын үтәү;

Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (дәлилле шикаятьләрнең) булмавы.

Гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара аралашуларының саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тиешле документларны тапшырганда – бер тапкырдан да артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмаганда);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә, үзара хезмәттәшлек таләп ителми;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тиешле документларны Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша җибәргәндә үзара хезмәттәшлек таләп ителми.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә аралашу вакыты 15 минуттан артмый. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып кабул итү урыны аша дәүләт хезмәтен күрсәтү үтәлми. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат белән гариза бирүче http://mincult.tatarstan.ru сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Порталында таныша ала.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гариза буенча башкарылмый.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган башка таләпләр

Министрлыкка гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән рәсмиләштерелгән очракта электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин»;

3 бүлектә:

атаманы түбәндәге редакциядә язырга:

«3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре»;

3.1 пунктындагы 3.1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара гаризалар төзү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

6) техник хаталарны төзәтү.»;

3.3 пунктында түбәндәге редакциядә язырга:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе Министрлыкның контроль һәм эш башкару бүлегенә (алга таба – Эш башкару бүлеге) гариза бирә.

Гариза түләүле хат белән почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә имзалана (раслана) һәм гомуми файдаланудагы электрон чыганаклардан һәм (яисә) мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, «Интернет» челтәре аша да тапшырыла.

Гариза шулай ук Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша да бирелергә мөмкин.

Түләүле хат белән почта аша яисә электрон рәвештә тапшырылган гариза гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

Гаризаны Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша электрон рәвештә бирү өчен гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында авторизация (теркәлә һәм шәхесен раслый) уза;

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында электрон гариза формасы таба;

Дәүләт хезмәт күрсәтү өчен тиешле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза форманы тутыра;

Документларны электрон рәвештә яисә документларның электрон күчермәсен электрон гариза формасына беркетә (таләп ителгән очракта);

Электрон рәвештә дәүләт хезмәт күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

Хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

Тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

Электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.»;

3.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә язырга:

«3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәтен алучы гариза бирүченең законлы вәкил булуын яисә вәкаләтле заты буларак эш итүченең вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла.

Гариза бирүче шәхсән үзе мөрәҗәгать иткән вакытта әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, белгеч гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә Эш башкару бүлеге белгече баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма рәвештә аңлатып, биргән документларны аңа почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Гариза биргәндә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша гаризаны теркәүдән баш тарту турында хәбәрнамә, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, мөрәҗәгать итүченең Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне эшли:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә яисә почта, электрон почта аша, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (теләгән очракта) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында ( гариза бирүче теләге буенча) бирелгән документларны кабул итү көне һәм вакыты турында тамга белән хәбәрнамәнең күчермәсен тапшыру;

гаризаны Татарстан Республикасы Мәдәният министрына (алга таба – Министр) электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша юллау.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гаризалар ял (бәйрәм) көннәрендә электрон формада кергән очраклардан тыш, гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Министрга юлланган гариза.»;

3.4 пунктындагы 3.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар гаризалар кергән вакыттан алып биш эш көне эчендә шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаларга җаваплар яки белешмәләр (документлар) булмау турында хәбәрнамәләр.»;

3.5 пунктындагы 3.5.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.5. Эш башкару бүлеге белгече:

теркәп җибәрелә торган хатны, бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне терки;

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада (шәхсән, почта аша, электрон почта аша, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (функцияләр) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында) күрсәтелгән ысул белән имзаланган бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә) бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура түбәндә күрсәтелгән вакыт эчендә башкарыла:

почта, электрон почта аша яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша бәяләмә (Министр тарафыннан бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә) бирелгән көннән алып бер эш көне эчендә юллана;

гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) шәхсән алу турында күрсәтелгәндә, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) бирү (җибәрү).»;

3.7 пунктындагы 3.7.9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.9. Эш башкару бүлеге белгече:

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән бергә җибәрелә торган хатны терки;

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада (шәхсән, почта, электрон почта аша, Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (функцияләр) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына) күрсәтелгән ысул белән яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә) бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

почта, электрон почта буенча яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша - Министрның үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәсенә (нәтиҗәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәгә) кул

куйган көннән бер эш көне эчендә яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмәне бирүдән баш тарту) җибәргән очракта;

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) алу турында гаризада шәхсән үзе алуы күрсәтелгән булса – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә).»;

5 бүлекнең 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5.6. Шикаять бирелгән көннән алдагы эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне тикшерү вакыты – теркәгән көннән 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Министрлык, Министрлыкның вазифаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы дәгъваланган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 1 нче номерлы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ регламентка
Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1нче номерлы кушымта

(форма)

Татарстан Республикасы мәдәният министрына

________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

________________________________________
(оешманың атамасы)

________________________________________
(почта һәм (яисә) электрон) адресы

________________________________________
(булган очракта) телефон номеры

ГАРИЗА

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма

________________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциячел оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры)

тарафыннан күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтнең

(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендә гамәлгә кергән 1096 номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеге нигезендә иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү исеме, хезмәт атамасын сайлау:
инвалидларны социаль-мәдәни реабилитацияләү яисә абилитацияләүне уздыру;
мәдәни-массакүләм чаралар оештыру һәм уздыру;
спектакльләр (театраль тамашалар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру);
концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру);
сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыру;
«мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендәге оешмаларның хезмәт күрсәтүләренең сыйфатын бәйсез бәяләү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендә имзаланган 256-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оешма-оператор тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү системасын популярлаштыру өлешендә мәдәният өлкәсендә оешмалар тарафыннан башкарыла торган мәгълүматны җыю, гомумиләштерү һәм анализлау буенча хезмәт күрсәтүләр, гражданнарны бәйсез бәяләүгә җәлеп итү;
мәдәни-массакүләм чаралар (лекторияләр, семинарлар, фестивальләр, мәдәни-агарту проектлары) оештыру һәм үткәрү;
музей экспозицияләрен (күргәзмәләрен) булдыру, күчмә күргәзмәләр оештыру;
спектакльләр булдыру;
концертлар һәм концерт программалары булдыру;
Россия Федерациясе халыкларының үзенчәлеген, мәдәниятен, телләрен һәм традицияләрен саклау һәм яклау бурычларын хәл итүне тәэмин итә торган өстәмә белем бирү өлкәсендә хезмәт күрсәтү (гражданнарны Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм традицияләре белән таныштыру);
нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
телепрограммалар җитештерү һәм тарату;
радиопрограммалар җитештерү һәм тарату;
музыкаль һәм мәдәни-агарту аудиовизуаль программалар җитештерү һәм тарату;
экскурсия программаларын оештыру)

тиешле критерийларга туры килү сыйфаты турында бәяләмә бирүегезне сорыйм.

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) түбәндәге адреска бирүне (юллауны) үтенәм:

(шәхсән үземә, почта аша, электрон почта аша, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында шәхси кабинетка)

Оешма чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциячел булмаган оешма түгеллеген һәм бер ел дәвамында әлеге иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүен раслыйбыз һәм аларның сыйфаты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендә гамәлгә кергән 1096 номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» карарның бәяләү критерийларына туры килүен җиткерәбез:

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау (күләме, вакыты, күрсәтү сыйфаты);

(иҗтимагый файдалы хезмәт башкаруда турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән граждан-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән оешма һәм хезмәткәрләр) тиешле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белем бирү, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуын, шундый затларның саны җитәрлек булуын раслау)

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның хезмәтне күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлеген раслау (суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, башка органнар тарафыннан бәяләмә бирүгә кадәр ике ел эчендә үз компетенцияләре нигезендә иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле гамәлләр (гамәл кылмауга) һәм (яисә) оешманың карары булмау)

(коммерциягә карамаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын раслау)

(дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендә имзаланган 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында оешманың булмавын раслау)

Раслаучы документлар түбәндәгеләр:
1.
2.
3.
һәм башкалар.

Вазифа фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

"____"____________20_____ел

Мөһер урыны (мөһер булган очракта)»;

Регламентка 4 нче номерлы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ регламентка
социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче номерлы кушымта

(форма)

Татарстан Республикасы мәдәният министрына
_________________________________________

(фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

______________________________________

(оешманың атамасы)

______________________________________

(почта һәм (яисә) электрон) адресы

______________________________________

(булган очракта) телефон номеры

ГАРИЗА

техник хаталарны төзәтү турында

_______________________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманың исеме)

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең сыйфатының тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә биргәндә җибәрелгән хата яки социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең сыйфатына туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итә.

Бирелгән_______________________________________________күрсәтелгән хата:

(бирелгән документ)

______________________________________________________________________________,

Дөрес мәгълүматлар: ________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтергә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйбыз.

Гаризаны карау нәтиҗәс буенча яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) түбәндәге адреска бирүне (юллауны) сорыйбыз:

_______________________________________________________________________________

(шәхсән үземә, почта аша, электрон почта аша, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында шәхси кабинетка)

Түбәндәге документларны кабул итәбез:

1. ____________________________________________________________________________

2. ____________________________________________________________________________

3. ____________________________________________________________________________

һәм башкалар.

_______________________________________________________________________________

Вазифа фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

"____"____________20_____ел

Мөһер урыны (мөһер булган очракта)».